**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН КӨЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**НИЖНЕКУЮКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422741 Республика Татарстан Атнинский район с. Нижний Куюк, ул.Татарстан, 71а Тел. 3-32-47

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл җирлеге Советы

**КАРАР**

«02» октябрь 2017 ел. № 55

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» гы 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 23 мартындагы «Җирле референдум турында» 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Түбән Көек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, 2017 елның 22 сентябрендәге «Референдум үткәрүне оештыру турында» 15 номерлы Түбән Көек авыл башкарма комитеты карары«, 2017 елның 22 сентябрендәге «Референдум үткәрүне оештыру турында» 54 номерлы Түбән Көек авыл җирлеге Советының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советы карар **бирде:**

1. 2017 елның 19 ноябренә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2018 елда үзара салым кертү өчен 18 яшькә җиткән, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган Түбән Көек авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрү белән килешәсезме?:

1. Түбән Көек, Югары Көек, Иске Шимбер, Яңа Шимбер авыллары территорияләрен төзекләндерү һәм чистарту
   -Түбән Көек һәм Югары Көек авылларында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау
2. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү.
   - Югары Көек һәм Түбән Көек авылларында янгын гидрантларын урнаштыру өчен төзелеш
   материаллары, җайланмалар сатып алу һәм хезмәт күрсәтү өчен түләү.
3. Җирле әһәмияттәге урам юлларына карата юл эшчәнлеге:

- төзелеш материаллары сатып алу, Иске Шимбер авылы урам юлларын ремонтлау һәм

төзекләндерү буенча хезмәтләр өчен түләү;

- төзелеш материаллары сатып алу, Яңа Шимбер авылы урам юлларын ремонтлау һәм

төзекләндерү буенча хезмәтләр өчен түләү.

"ӘЙЕ" "ЮК"

3. Түбән Көек авыл җирлегенең сайлау комиссияләренә, гамәлдәге законнар нигезендә, «Түбән Көек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

4. Аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны экономияләү очрагында, әлеге акчалар планлаштырылган эшләрне башкару өчен акча җитәрлек булмаган юнәлешләрне финанслауга юнәлтелә.

5. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру, «Этнә таны» район газетасында бастырып чыгару һәм http://atnya.tatarstan.ru рәсми сайтка урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль
районы Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Мөхәммәтгалиев Ф.Т.